КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 15 декабрь г.Казань № 1146

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфра-структурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен күздә тотылган мөлкәт исемлегенә кертелгән дәүләт мөлкәтен арендага бирү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2016 ел, 23 декабрь, 976 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфра-структурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен күздә тотылган мөлкәт исемлегенә кертелгән дәүләт мөлкәтен арендага бирү тәртибен һәм шартларын раслау турында» 2016 ел, 23 декабрь, 976 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемендә һәм 1 пунктында «(кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш)» сүзләрен «(хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш)» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган, өченче затлар хокукларыннан ирекле (кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш) һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү инфраструктурасын төзи торган оешмаларга бирү өчен күздә тотылган мөлкәт исемлегенә кертелгән дәүләт мөлкәтен арендага бирү тәртибендә һәм шартларында:

исемендә «(кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш)» сүзләрен «(хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш)» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта:

«(җир кишәрлекләреннән тыш)» сүзләрен төшереп калдырырга;

«(кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш)» сүзләрен «(хуҗалык алып бару хокукыннан, оператив идарә итү хокукыннан, шулай ук кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының мөлкәт хокукларыннан тыш)» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ пункт өстәргә:

«$2^1$. Әлеге Тәртипнең 3 – 12 пунктлары нигезләмәләре әлеге Тәртипнең 1 пукнтында күрсәтелгән исемлеккә кертелгән җир кишәрлекләрен арендага бирү белән бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагылмый.

Әлеге Тәртипнең 1 пукнтында күрсәтелгән исемлеккә кертелгән җир кишәрлекләрен арендага бирү тәртибе һәм шартлары граждан законнары һәм җир законнары нигезендә билгеләнә.»;

10 пунктның беренче җөмләсендә «Мөлкәтне арендага алган һәм» сүзләреннән соң «авыл хуҗалыгы кооперативлары булган яки» сүзләрен өстәргә;

11 пунктта «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына бирелгән» сүзләреннән соң «авыл хуҗалыгы кооперативлары булган яки» сүзләрен өстәргә;

12 пункт үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин